**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 96** **04.06.2018**

**«Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. «Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәтенә түләү айлык акчалата түләү рәвешендә башкарыла. Акчалата түләү күләме 2 нче кушымтада бирелә. Айлык акчалата бүләкләүдән тыш, җирлек башлыгына өстәмә рәвештә билгеләнә:

- айлык акчалата бүләкләүнең 38,75 проценты күләмендә айлык акчалата түләү;

- нигезләмәнең 2.3 пунктында билгеләнгән күләмдә тиешле еллар эшләгән өчен акчалата бүләкләүгә айлык өстәмә».

1.2. 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Югары Налим авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ verkhnenalimskoeСовет рәисе.htm) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Н. Николаева**

Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге
Советының 2018 елның 04
июндәге 96 номерлы карарына
кушымта

Югары Налим авыл җирлеге башлыгына
акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 15 300 |